КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 декабрь г.Казань № 1306

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт учреждениеләренең һәм дәүләт унитар предприятиеләренең төп чараларына капитал салулар рәвешендә бюджет инвестицияләрен һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә субсидияләр күздә тота торган программаларны формалаштыру һәм тормышка ашыру тәртибен раслау турында һәм бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру буенча күчеш нигезләмәләрен билгеләү хакында» 2007 ел, 29 декабрь, 805 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт учреждениеләренең һәм дәүләт унитар предприятиеләренең төп чараларына капитал салулар рәвешендә бюджет инвестицияләрен һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә субсидияләр күздә тота торган программаларны формалаштыру һәм тормышка ашыру тәртибенә, 3.10 пунктның беренче абзацында «Дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә физик затларга, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм эшмәкәрлек эшен башларга планлаштыручы гражданнарга хезмәт күрсәтүгә йөз тоткан хезмәт күрсәтү үзәкләрен һәм юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм эшмәкәрлек эшен башларга планлаштыручы гражданнарга хезмәт күрсәтүгә йөз тоткан күп функцияле үзәкләрне үстерү турында» 2017 ел, 29 декабрь, 1083 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацында «Бюджетларына кече һәм урта эшмәкәрлеккә, крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп, дәүләт ярдәме күрсәтү өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу шартларын һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга таләпләрне раслау турында» 2015 ел, 25 март, 167 нче боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә, шулай ук «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен бюджетларына субсидия бирелә торган Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган, «Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм индивидуаль эшмәкәрлек инициативасына ярдәм күрсәтү» илкүләм проект составына керә торган федераль проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектларының максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга карата таләпләрне, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга карата таләпләрне раслау турында» 2021 елның 26 мартындагы 142 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында физик затларга, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм эшмәкәрлек эшен башларга планлаштыручы гражданнарга хезмәт күрсәтүгә йөз тоткан хезмәт күрсәтү үзәкләрен һәм юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм эшмәкәрлек эшен башларга планлаштыручы гражданнарга хезмәт күрсәтүгә йөз тоткан күп функцияле үзәкләрне урнаштыру схемасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Идарә итүгә дәүләт заказының үтәлеше нәтиҗәләрен әзерләгәндә һәм анализлаганда Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарының мәгълүмати хезмәттәшлеге турында» 2008 ел, 14 май, 315 нче;

«Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 15 гыйнвар, 10 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 15 гыйнвар, 10 нчы карарына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен финанслау нормативларын раслау хакында» 2013 ел, 11 апрель, 246 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен

оештыру турында» 2013 ел, 15 гыйнвар, 10 нчы карарына үзгәреш кертү хакында» 2013 ел, 28 июнь, 447 нче;

«Сәнәгать (индустриаль) паркларын төзү» чарасы буенча федераль субсидия алуга Татарстан Республикасыннан уртак гаризага кертүгә дәгъва итүче гаризаларны сайлап алу тәртибен раслау турында» 2014 ел, 6 октябрь, 728 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм кайберләре үз көчен югалткан дип санау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 июль, 512 нче карарындагы 3 пункты;

«Дәүләт учреждениеләре яки муниципаль учреждениеләр һәм дәүләт унитар предприятиеләре яки муниципаль унитар предприятиеләр булмаган юридик затларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бюджет инвестицияләре бирүгә бәйле рәвештә төзелә торган шартнамәләргә карата таләпләр билгеләү турында» 2016 ел, 9 август, 545 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 29 декабрь, 1083 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 29 декабрь, 1306 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында физик затларга, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм эшмәкәрлек эшен башларга планлаштыручы гражданнарга хезмәт күрсәтүгә йөз тоткан хезмәт күрсәтү үзәкләрен һәм юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм эшмәкәрлек эшен башларга планлаштыручы гражданнарга хезмәт күрсәтүгә йөз тоткан күп функцияле үзәкләрне урнаштыру схемасы

| Т/с | Муниципаль берәмлек, торак пункт исеме | Халык саны[1] | Объект тибы | Хезмәтләр күрсәтү объекты урнашкан оешма исеме | Адресы | Бизнес-тәрә-зәләр саны | Ачылу датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Казан шәһәре | 1 257 341 | бизнес-офис (бизнес өчен күп функцияле үзәк)[2] | «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Петербург урамы, 28 нче йорт | 3 | 22.09.2017 |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:
бизнес-тәрәзә – эшмәкәрлек субъектларына һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген башларга планлаштыручы гражданнарга

[1]2021 елның 1 гыйнварына Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең мәгълүматлары буенча
[2]Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

мәгълүмат бирү һәм хезмәтләр күрсәтү, сервислар бирү һәм башка ярдәм күрсәтү чаралары өчен билгеләнгән, махсус җиһазландырылган урын;

бизнес-офис – керү ишеге аерым булган бүлмәдә, бинада урнашкан, өч һәм аннан күбрәк бизнес-тәрәзәдән торган бизнес-зона;

бизнес өчен күп функцияле үзәк – «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның таләпләренә җавап бирә торган һәм юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген башларга планлаштыручы гражданнарга дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә вәкаләте булган оешма.